| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** 11.10.2023 | Казан ш. | **БОЕРЫК** №1174-п |

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 08.12.2021 №1385-п боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 декабрендәге 906 номерлы карары нигезендә б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау турында» 08.12.2021 №1385-п боерыгына (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 21.02.2022 №134-п, 03.03.2023 №205-п боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» сүзләре белән алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәдә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләре белән алмаштырырга;

3.1 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет төзү тәртибе» сүзләре белән алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган, әлеге башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнә торган, әлеге республика башкарма хакимият органнары каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмый торган» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.В. Шадриков